КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 июль г.Казань № 544

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 26 сентябрь, 682 нче карары белән Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 26 сентябрь, 682 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 10 ноябрь, 861 нче, 2021 ел, 14 апрель, 247 нче, 2024 ел, 9 февраль, 73 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем

бирү оешмаларында, шулай ук озак вакытлы дәвалануга мохтаҗ укучылар өчен Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларга, яшәүчеләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы карамагындагы төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм шифаханә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»2009 ел, 08 апрель, 208 нче карары белән билгеләнгән нормалар буенча»;

2.3 пунктчада:

«гомуми белем бирү оешмалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«кадет мәктәбе» сүзләреннән соң «, интернаты булган» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

«2.5. Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында яшәмәүче сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, җан башына кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән кимрәк булган гаиләләрдән белем алучылар, күченеп килергә мәҗбүр булганнарның гаиләләрдән укучылр арасыннан укучыларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган күләмдә Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмасына һәр көн саен ике мәртәбә кайнар азык белән тәэмин итү юлы белән.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин